Мәмәшир авыл җирлеге Советы

КАРАР

08.11.2024 ел № 1

**Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 8 нче ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

“Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Тәмәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән ,1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдән,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2025 елда һәр бәлигъ булган кешегә 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - Тәмәй авылының урам-юл челтәренә вак таш салу, ремонтлау, карап тоту,вак таш сатып алу,автомобиль күперен ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (тирәннән суырта торган насослар һәм электр җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, Тәмәй авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Тәмәй авылында урам яктыртуны көйләү өчен, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Тәмәй авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),

(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, җәен территориянең печәнен чабу, материаллар сатып алу һәм ташу);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантлары һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (җәяүлеләр күперен төзү һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **49** кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **27** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **27** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Мәмәшир авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Тәмәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган куп балалы гаилэлэрдэн,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәклэрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2025 елда һәр бэлигъ булган кешегә 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә илешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - Тәмәй авылының урам-юл челтәренә вак таш салу, ремонтлау, карап тоту,вак таш сатып алу,автомобиль күперен ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (тирәннән суырта торган насослар һәм электр җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, Тәмәй авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Тәмәй авылында урам яктыртуны көйләү өчен, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Тәмәй авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),

(спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, җәен территориянең печәнен чабу, материаллар сатып алу һәм ташу);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантлары һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　И.Г.Әхмәтҗанов